СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 Баулы шәһәре № 16

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 159 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 25 февралендәге 196 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 264 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19нчы статьяның 3нче пункты 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр (хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш);»;

34нче статьяның 4нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин